**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЧЕПЧУГОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422736, Республика Татарстан, Высокогорский район, с. Чепчуги, ул.Советская,10Б

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЫПЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422736, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Чыпчык авылы, Совет ур., 10Б

тел./факс 8(84365) 3-29-89, e-mail: Chep.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**28 июня 2024 г.** **№ 10**

**«Биектау муниципаль районы Чепчуг авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында " 2021 елның 26 октябрендәге 31 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чепчуг авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча, Биектау муниципаль районы Чепчуг авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТӘ**:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Чепчуг авыл җирлеге Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы Чепчуг авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»2021 елның 26 октябрендәге 31 номерлы карары белән расланган адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче бүлекнең 1.2 пунктының 10 нчы абзацында «әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзен «гариза белән»гә алыштырырга.

1.2. 2.3.2 пунктында. 2.3 бүлектә «берләштерелергә мөмкин» сүзен «берләштерелә»сүзе белән алыштырырга.

1.3. 2.4 бүлегенең 2.4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты:

- кәгазьдә гариза биргән очракта-гариза килгән көннән алып 10 эш көненнән дә артык булмаган вакытта;

- электрон документ формасында гариза биргән очракта-гариза килгән көннән алып 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта.

Алдан (актив) режимда муниципаль хезмәт күрсәтелгән очракта - регламентның 1.6 пунктында күрсәтелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгән көннән алып 3 эш көне.

Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты гариза теркәлгән көннән соң икенче көнне исәпләнә башлый.»

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) :http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

Башкарма комитет җитәкчесе
Чепчуг авыл җирлеге И. Р. Җиһаншин